КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2022 ел, 19 февраль г.Казань № 141

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының кайбер карарларына үзгәрешләр кертү турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы дәүләт мәдәният учреждениеләре хезмәткәрләренең хезмәт өчен түләү шартлары турында» 2018 ел, 31 май, 413 нче карары (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2020 ел, 30 декабрь, 1245 нче, 2021 ел, 26 июль, 645 нче, 2021 ел, 30 октябрь, 1030 нчы карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) белән расланган Татарстан Республикасы дәүләт башкарма сәнгать учреждениеләре мәдәният, сәнгать һәм кинематография хезмәткәрләре вазыйфаларының һөнәри квалификация төркемнәре хезмәткәрләренең хезмәте өчен түләү шартлары турында нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

4.2 пунктның өченче абзацында «театрларда» сүзләреннән соң «һәм концерт учреждениеләрендә» сүзләрен өстәргә;

4.4 пунктта:

беренче абзацта «театрларда», «театрларның» сүзләреннән соң тиешенчә «һәм концерт учреждениеләрендә», «һәм концерт учреждениеләренең» сүзләрен өстәргә;

дүртенче абзацта «театрларда» сүзләреннән соң «һәм концерт учреждениеләрендә» сүзләрен өстәргә;

2. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Академия» исеменә ия булган театрларда эшләгән өчен түләүләр турында» 2017 ел, 18 сентябрь, 677 нче карарына (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2020 ел, 6 март, 175 нче, 2021 ел, 29 март, 189 нчы, 2021 ел, 6 май, 316 нчы карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

исемдә «театрларда» сүзеннән соң «һәм концерт учреждениеләрендә» сүзләрен өстәргә;

преамбулада «театрлар» сүзеннән соң «һәм концерт учреждениеләре» сүзләрен өстәргә;

1 пунктта «театрларда» сүзеннән соң «һәм концерт учреждениеләрендә» сүзләрен өстәргә;

2 пунктта «театрларга» сүзеннән соң «һәм концерт учреждениеләренә» сүзләрен өстәргә;

әлеге карарга теркәлгән кушымтада:

исемдә «театрларда» сүзеннән соң «һәм концерт учреждениеләрендә» сүзләрен өстәргә;

«Театр исеме» графасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Театр яисә концерт учреждениесе исеме»;

«В.И. Качалов исемендәге Казан академия рус Зур драма театры» Татарстан Республикасы Дәүләт бюджет мәдәният учреждениесе» юлыннан соң түбәндәге эчтәлекле юллар өстәргә:

| | |
|---|---|
| «Татарстан Республикасының Дәүләт симфоник оркестры» Татарстан Республикасы дәүләт автоном мәдәният учреждениесе | 3 975,7»; |

«Барлыгы» юлында «161 824,3» саннарын «165 800,0» саннарына алмаштырырга.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин